КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 9 сентябрь г.Казань № 807

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар төзү белән бәйле торак-төзелеш коопера-тивлары эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 31 октябрь, 974 нче карары белән расланган Күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар төзү белән бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар төзү белән бәйле торак-төзелеш коопера-тивлары эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 31 октябрь, 974 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 18 июнь,

501 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар төзү белән бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзүдә катнашучыларның акчасын җәлеп итүче затларны тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү;»;

түбәндәге эчтәлекле $5^1$ нче пункт өстәргә:

«$5^1$. Күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзүдә катнашучыларның акчасын җәлеп итүче затларны план буенча һәм планнан тыш тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү, «Күпфатирлы йортларны һәм бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы һәм Россия Федерациясе Торак кодексының $123^2$ статьясы (торак-төзелеш кооперативы өчен) белән билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләрнең нигезләре буенча һәм аларны үтәп гамәлгә ашырыла.»;

8 нче пунктта «2014» саннарын «2004» саннарына алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин